19.11.2019 №1

# РЕШЕНИЕ (КАРАР)

## 2019 нчы елның 17 нче ноябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Килдебәк торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 21 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып, 2019 нчы елның 17 нче ноябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең Килдебәк торак пункты территориясендә гражданнар җыены кабул иткән карар нигезендә:

Килдебәк авыл җирлегенең Килдебәк авылы халык җыенында катнашу өчен сайлау хокукына ия булган 447 кеше кертелгән, халык җыенында катнашучылар 234, бу исемлеккә кертелгән кешеләрнең 52,34% ын тәшкил итә

Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә билгеләнде:

«Әйе» позициясе өчен 234 кеше тавыш бирде, бу гражданнар җыенында катнашучыларның 100% ын тәшкил итә, «юк» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде,бу 0% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы карар итә:

1.2019 нчы елның 17 нче ноябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Килдебәк торак пункты территориясендә гражданнар җыенын үткән дип, аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2."2020 нче елда Саба муниципаль районының Килдебәк авыл җирлеге Килдебәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны Килдебәк авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау өчен тотарга игән сорау белән килешәсезме? диган карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kildebiak бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Заһидуллин